ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДӨБЪЯЗ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Дубъязы, ул. Ленина, 28

Тел./факс: +7(84365) 61-2-63, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

20 ноябрь 2019 ел № 144

**Җир салымы турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, “Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында”, 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру кысаларында, Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Уставы белән эш йөртеп, Дөбъяз авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымын (алга таба – салым) билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Түбәндәге салым ставкаларын билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды милкендә булган җир кишәрлекләренә карата 0,001 процент күләмендә;

2) түбәндәге җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент күләмендә:

- авыл хуҗалыгы билгеләнешле җирләргә яки Дөбъяз авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары җирләре составына кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган;

- торак фонды һәм торак-коммуналь комплексның инженер инфраструктурасы объектлары (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженер инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килгән җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән кала) яки торак төзелеше өчен алынган (тәкъдим ителгән);

- эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек, шулай ук “Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон белән күздә тотылган гомуми кулланылыштагы алынган (тәкъдим ителгән) җир кишәрлекләре;

- шәхси торак төзелеше объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән; шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт яны кишәрлекләре);

- оборона, куркынычсызлык һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен тәкъдим ителгән, әйләнешендә Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән.

3) түбәндәге җир кишәрлекләренә карата 1,3 процент күләмендә:

- торак пунктлары җирләре составында сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте объектлары булган;

- торак пунктлары җирләре составында җитештерү һәм административ биналар, корылмалар, сәнәгать, коммуналь хуҗалык, материаль-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, урнаштыру һәм әзерләү корылмалары урнаштыру өчен билгеләнгән;

4) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 процент күләмендә.

3. Салым буенча хисап чоры, салымны һәм аванс түләүләрен түләү тәртибе һәм сроклары.

3.1. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары итеп календарь елының беренче, икенче һәм өченче кварталлары санала дип билгеләргә.

3.2. Салым буенча салым һәм аванс түләүләрнең түләү тәртибен һәм срокларын түбәндәгечә итеп билгеләргә:

3.2.1. Салым чоры тәмамлангач түләнергә тиешле салым түләүче оешмалар өчен салым суммасы узган салым чоры артыннан килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча түләнелә.

3.2.2. Хисап чоры квартал буларак билгеләнгән салым түләүчеләр салым буенча аванс түләүләре суммаларын агымдагы салым чорының беренче, икенче, өченче кварталы беткәч, җир кишәрлегенең кадастр бәясе процент өлешеннән билгеле салым ставкасының дүрттән бере буларак исәплиләр.

3.2.3. Салым түләүче физик затлар өчен салым суммасы узган салым чоры артыннан килүче елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләнелә.

4. Җир кишәрлекләренең кадастр бәяләре салым түләүчеләргә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләгән башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнелә торган тәртиптә җиткерелә икәнлеген билгеләргә.

5. Салым түләүче оешмалар һәм физик затлар өчен әлеге Карар белән билгеләнгән ташламалар бирүнең түбәндәге тәртибен һәм нигезләрен билгеләргә:

5.1. Салым түләүче оешмалар салым органына ташламага хокукны раслаучы документларны, салым декларациясен бирү өчен Россия Федерациясе Салым кодексы белән билгеләнгән срокларда тәкъдим итәләр.

5.2. Оешмалар өчен, әлеге Карарның 7 пунктында күздә тотылган ташламаларга хокукны раслаучы документлар булып, әлеге Карарга 1 кушымтадагы форма нигезендә салым ташламаларын исәпләү тора. Исәпләү ике нөсхәдә, җирле бюджетны башкару өчен вәкаләтле органга визалау өчен тәкъдим ителә. Визалаганнан соң беренче нөсхә салым органына тәкъдим ителә, икенчесе җирле бюджетны башкару өчен вәкаләтле органда кала.

5.3. Салым түләүче физик затлар өчен әлеге Карар белән билгеләнгән ташламалар, салым түләүче тарафыннан салым органына бирелә торган ташламага хокукны раслаучы документлар нигезендә тәкъдим ителәләр.

6. Салым салу объеклары булып танылмый икәнлеген билгеләргә:

а) Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештән алынган җир кишәрлекләре;

б) Россия Федерациясе халыкларының аеруча да кыйммәтле мәдәни мирас объектлары, Бөтендөнья мирас объектлары исемлегенә кертелгән объектлар, тарихи-мәдәни тыюлыклар, археологик мирас объектлары, музей-тыюлыклар булган, Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләре;

в) урман фонды җирләре составыннан җир кишәрләекләре;

г) су фонды составында дәүләт милкендәге су объектлары булган Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләре;

д) күпфатирлы йортның гомуми милке составына кергән җир кишәрлекләре.

7. Түбәндәге салым ташламаларын билгеләргә:

7.1. Җир салымын түләүдән азат ителәләр:

- оешмалар – гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата (урман, урман-парклар, парклар, скверлар, шоссе, проспектлар, урамнар, тыкрыклар, юллар, мәйданнар, тукталышлар, һәйкәлләр, яр буйлары, колонкалар, су кудыру башнялары, чишмәләр, коелар, артезиан скважиналары);

- оешмалар һәм учреждениеләр, зиратлар, хайваннарны күмү урыннары һәм гражданнар каберлекләре булган җир кишәрлекләренә карата;

- Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, башка сугыш хәрәкәтләре катнашучылары, шулай ук закон тарафыннан Бөек Ватан сугышында катнашучылар социаль гарантияләре һәм ташламалары кагылган гражданнар. Ташлама бирү өчен нигез булып Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы яисә сугышта катнашучы таныклыгы, башка билгеле таныклыклар тора.

Физик затлар өчен билгеләнгән салым ташламалары файда алуга юнәлдерелгән (коммерциячел куллану), рөхсәт ителгән куллану төрләре белән җир кишәрлекләренә карата гамәлдә түгел.

7.2. Җир салымын түләүдән азат ителгән юридик затлар һәм гражданнардан, алар тарафыннан җир кишәрлекләрен арендага (куллануга) биргәч, арендага (куллануга) биргән мәйданнан җир салымы алына.

7.3. Җирнең кадастр бәясеннән түбәнәйтелгән ставкасын куллану рәвешендә:

- федераль бюджеттан, Татарстан Республткасы бюджетыннан, Биектау муниципаль районының җирле бюджетыннан финанслана торган казна учреждениеләренә, бюджет һәм автоном учреждениеләргә 0,07% күләмендә;

- 1-3 категория гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын төзүгә һәм куллануга бирелә торган кишәрлекләргә карарта 0,05%.

8. Үз көчен югалткан дип таныргга:

Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында”, 2015 елның 24 ноябрендәге 11 номерлы карарын;

Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының “Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында”, 2015 елның 24 ноябрендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”, 2017 елның 14 августындагы 58 номерлы карарын.

9. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми

сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә.

10. Әлеге Карар үз көченә 2020 елның 1 нче гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин ул рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң бер айдан да алда һәм җир салымы буенча чираттагы салым периодының 1 нче числосыннан да алда түгел.

11. Әлеге Карарның 3 пункты 3.2 пунктчасы 2021 елның 1 нче гыйнварыннан үз көчен югалта.

12. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Дөбъяз авыл җирлеге башлыгы Ә.С. Низамов